Республика Татарстан

ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**“08” 06 2018г.** **№ 49**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районында гражданнар оборонасы буенча чаралар
үтәлешен тәэмин итүдә штаттан тыш формированиеләр
оештыру турында

1998 елның 12 февраленнән булган “Гражданнар оборонасы” турындагы 28 санлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябреннән булган “Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы 804 санлы нигезләмәсе, Россия Федерациясе гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш вазгыятьләр һәм стихияле бәла-казалар нәтиҗәләреннән арыну министрлыгының 2005 елның 23 декабреннән булган “Штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен оештыру тәртибен раслау турында”гы 999 санлы боерыклары, 2014 елның 18 декабреннән булган “Гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүдә штаттан тыш формированиеләр типовой тәртибен оештыруны раслау турында”гы 701 санлы карары, Татарстан Республикасының 2016 елның 19 гыйнварыннан булган 35 санлы күрсәтмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Ютазы районы кулланучылар берләшмәсе җитәкчесенә гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча түбәндәге штаттан тыш формированиеләр оештырырга тәкъдим итәргә:

- күчмә азык-төлек белән тәэмин итү пункты;

- күчмә туклану пункты;

- әйберләр белән тәэмин итү күчмә пункты.

2. Сәүдә һәм туклану хезмәте җитәкчесенә:

Гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүдә оешма белән җитәкчелек итүне, штаттан тыш формированиеләрне комплектлаштыру, корал-җиһаз белән тәэмин итү һәм хәзерләү эшен гамәлгә ашырырга;

гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүдә территориаль штаттан тыш формированиеләрнең, гадәттән тыш вазгыятьләр барлыкка килгәндә һәм үсеш алганда, закончалыкта билгеләнгән тәртипкә ярашлы, ТР Ютазы муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш вазгыятьләрне бетерү, шулай ук гражданнар оборонасы планына ярашлы, гражданнар оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл итү һәм халыкны саклау өчен ТР Ютазы муниципаль районы Гражданнар оборонасы җитәкчесе карары буенча җәлеп ителүен билгеләргә.

3. ТР Ютазы муниципаль районы оешмаларына гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәүдә штаттан тыш авария-коткару формированиеләре һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәүдә Россия Федерациясе гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш вазгыятьләр һәм стихияле бәла-казалар нәтиҗәләреннән арыну министрлыгының 2005 елның 23 декабреннән булган “Штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен оештыру тәртибен раслау турында”гы 999 санлы боерыклары таләпләренә, 2014 елның 18 декабреннән булган “Гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүдә штаттан тыш формированиеләр типовой тәртибен оештыруны раслау турында”гы 701 санлы карарына ярашлы оештыруны тәкъдим итәргә.

4. “Татарстан Республикасы буенча 11 санлы федераль янгын хезмәте бүлеге” 42 санлы санлы янгын-коткару часте ФДКУга районның икътисад объектларында гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүдә штаттан тыш

формированиеләр оештыру буенча контроль уздырганда һәм эшчәнлекне координацияләгәндә методик ярдәм күрсәтергә.

5. Ютазы муниципаль районы башлыгының 2015 елның 25 сентябреннән булган "Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итүдә штаттан тыш формированиеләр оештыру турында"гы 74 санлы Нигезләмәсен көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге нигезләмә үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Р.М.Нуриев